6+

БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ

# Сабантуй.рт

№1, 2025

Шәлегә сәфәр

ТАТАРЧА ТУҢДЫРМА

МИЛЛИ БӘЙРӘМ: НАРДУГАН

Тәмле аюлар



«Раян» вокаль ансамбле: «Без – Теләче йолдызлары!»

экосәхифә

# ГОРКИ-ӘМӘТ УРМАНЫ

**КАЗАННЫҢ СОВЕТ РАЙОНЫНДА УРНАШКАН ЭКОЛОГИЯ ЮНӘЛЕШЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕ 79 НЧЫ ЛИЦЕЕ УКУЧЫЛАРЫ ТАБИГАТЬ САГЫНДА ТОРА. БҮГЕН АЛАРНЫҢ ТӨП КҮЗӘТҮ МӘЙДАНЫ – ГОРКИ-ӘМӘТ УРМАНЫ.**

**Белеп тор!** Бу – Казандагы иң яшь паркларның берсе, 2016 нчы елның декабрендә ачыла.

**Эко**

Әмәт урманы экология җирлеге буларак билгеле. Бирендә экосукмаклар ясалган, балалар өчен экомәйданчык бар. Горки урманы исә спорт мәйданчыгы ролен үти.

**Бу – кызык!**

Бельгия галимнәре урман-парклар янында яшәүче балалар акыллырак булуын дәлилләгән. Шуңа да 79 нчы лицей укучылары парктан кайтып керми!

**Сан** Урман-паркның гомуми мәйданы 87 гектардан артык.

**Мөһим!**

Бирендә Кызыл китапка кертелгән үсемлекләр һәм җанварларны очратырга мөмкин. Кабар агачы, урман зелпесе, миләш чыпчыгы, күкканат шундыйлардан.

**Ә сез беләсезме?**



1 Урмандагы агачларда мүк горизонтның кайсы ягында үсә?

2 Грушаны хәтерләтә торган бу гөмбәне кем белә?

3 Бу үсемлек ничек атала?

Җавапларны sabantui@bk.ru адресына юлла. Беренче дөрес җавап бирүчене 79 нчы лицейдан бүләк көтә.